
ISSN 0868-4545

Салават күпере

Балалар журналы





Һәр фасыл үзенчә ямьле, әйеме?!

Кыш – ябалак-ябалак булып яуган карлары, агач-куакларны сарган ап-ак бәсләре, дуамал бураннары, тәрәзә пыялаларындагы кар абагалары... белән матур.

Яз – ләйсән яңгырлары, җылы яклардан кайткан кошларның тәүге чыр-чулары, кәгазь көймәле гөрләвекләре, кар эрүгә борын төрткән чирәмнәре, умырзаялары... белән гүзәл.



© "Салават күпере", 2002 ел

Җәй – алсу, сусыл җиләкләре, хәтфә үләннәре, исәп-хисапсыз чәчкәләре, талгын гына тирбәлешкән иген кырлары, шифалы, җылы яңгырлары... белән сокланггыч.

Көз...

Әйе, көз дә – матур, гүзәл, сокланггыч.

Ә-әнә, Сентябрь малае, шукланып, агачлардагы алтынсу, сары яфракларны җиргә сибеп йөри...

Ә-әнә, Җил малае әлеге яфраклар белән куышлы уйный...

Кояшсылу аларның кыланмышларын сокланып күзәтә. Үзе дә сизмәстән, уенга кушыла...

Ә-әнә, чәчәктәй киенгән малайлар һәм кызлар, газиз әти-әниләре, кадерле әби-бабайлары, абый-апалары белән җитәкләшеп, ясле-бакчага, мәктәпкә ашыга. Аларны, Кояшсылу кебек елмаеп, тәрбияче апалар, укытучылар каршы ала...

И ямьле дә соң, күңелле дә соң дөнья!

Шулай бит?!

Рәссам Алла АЙСИНА



Мин – татар баласы!

* * *

Кояш батыш якларында
Балкый Казан каласы.
Нигә шуны белмәскә?
Мин бит – татар баласы!

Казан бик матур каладыр,
Хыялым – шунда барасы.
Нигә хыялланмаска?
Мин бит – татар баласы!

Их, Казанга барып-укып,
Ныклы белем аласы.
Нигә әле укымаска?
Мин бит – татар баласы!

Татар булып, илне сөеп,
Киләә алга барасы.
Нигә алга бармаска?
Без бит – татар баласы!

Алсу һәм Айгөл
МӨНИРОВАЛАР.
Актаныш, Яңа Җияш.

* * *

Яхшы белсәм дә рус телен,
Инглиз телен белсәм дә,
Онытмамын татар телен
Кайда гына йөрсәм дә.

Илсөяр НИЗАМОВА.
Казан.



Беркөнне мин күршеләргә кердем. Аларда бик эссе иде.

– Илназ, син нишләп түбәтәеңне салмыйсың? Эссе бит, – дидем мин күршемә.

– Нигә салыйм мин аны, мин бит – татар баласы! – диде Илназ.

Илнара МАННАПОВА.
Биектау, Суыксу.



Мин – үз илемнең нечкә күңелле бер баласы. Мин – татар авылында яшәүче бер кыз.

Минем телем – татар теле.

Чит җирләргә китсәң дә, үз телеңне, милләтеңне онытмаска кирәк.

Илнара ВӘЛИЕВА.
Мөслим, Баек.



Бигрәк зур һәм матур минем Татарстан.
Матур аның шәһәрләре, авыллар һәм күлләре.
Шул гүзәллек өчен яратам:
Мин дә синдә татар баласы.

Синең йолаларың матур,
Бәйрәмнәрең күркәм.
Матурлыгыңа синең сокланам.
Татар баласы булуым белән горурланам!

Айрат ХӘНИПОВ.
Ютазы, Бәйрәкә.

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА



БЕРТУГАН ГРИММНАР

Дөньяда булмаган илдә

Бервакыт дөньяда булмаган бер гаҗәеп илдә булдым мин. Шунда йөргәндә киң ябалдашлы юкә агачының ботакларында исәпсез-хисапсыз кайнар коймаклар үскәнен күрдем. Шуннан соң күктә балыкларның пырдымсызланып, ыгы-зыгы килеп йөзгәннәрен дә, болытларның берөзлексез чайкалганнарын да күрдем әле.

Янә күрдем: ике карганың болында печән чапканын, ике озынборынның күпер төзегәнен, ике баканың он тарттырганын, ике кәҗәнең мич якканын һәм бер сыерның шул мичкә ипи тыкканын...





Бу илдә чебеннәр шундый зу-у-ур – бездәге кәҗәләр хәтле! Бигрәкләр дә сәер хәлләр инде менә...

Ә хәзер, йә, ач тәрәзәне, очып керсен мин күргәннәр.

Урысчадан Л.Лерон тәрҗемә кылды.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ




Лəбиб Лерон

Шундый–шундый хəллəр

Рəссам
Фəрит Муллахмəт
Шалтмылтфильм

Олы Имəн мəктəбендə
Шундый хəл булды беркөн...
(Мондый хəлнең булган чагын
Хəтерлəмидер беркем!)


...Кəрим, Сəлим һəм Хəким
Уйнаганда туп тибеп,
Челпəрəмə килде тəрəз
Пыяласы туп тиеп!






Ни хикмəттер, малайларны
Ник берəрсе орышсын.
«Кем ватты?» да «Кем ватты?» дип
Никлəр берсе сорашсын...

Киресенчə: «Ачуланмыйк,
Алыйк мактап та», – дилəр...
«Бик шəп футболчылар үсə
Безнең мəктəптə!» дилəр...






Бер агарды, бер кызарды
Малайларның йөзлəре,
Хəтта директор абый да
Мактап алгач үзлəрен...


...Дəрес бара. Укытучы
Мəзəк сөйлəп көлдерə.
Кая ул өй эшен сорау, –
Көлə алсаң – көл генə!



Дәрес ахыры җиткәндә
«5»ле куя һәркемгә...
Мәзәк сөйләп, ике «5»ле
Алды хәтта Хәким дә!



...Кәгазь күгәрченнәр ясап
Очырганда һәрберсе,
Җырлап кына үтеп китә
Татар теле дәресе!



...Тәнәфестә кызыйларны
Куркытып вә өркетеп,
Маймыллана малай-шалай
Мәктәпне дер селкетеп.




Кайсы куа, кайсы кача –
Куышалар, янәсе...
Авыздан куык чыгарып,
Сагыз чәйни һәммәсе!



Укытучылар да бергә
«Әбәк-чәбәкле» уйный;
Тик нигәдер Хәким генә
Аңлый алмый һич шуны!



...Гел-гел шулай икән, диеп,
Уйлый күрмә тагы син:
Болар – төштә күргән хәлләр...
Ни булыр иртәгесен?





Ләйсән белән Айсылу


– Фотографны көтә-көтә,
Арып беткәнбез инде.
Сурәткә төшәр алдыннан
Йоклап киткәнбез инде...
(Пермь, Барда, Бичура)


Камилә, 1 яшь 3 ай

– Китмә инде, Шаян, әйдә,
Кил, коеныйк әле, дим...
– Хәзер, хәзер, көт, Камилә...
Мәче күрдем әле мин!
(Казан)


Кәримә, 8 яшь

– Матур-матур бу гөлләргә,
Йәле, йәле, карале...
Шушы гөлләр белән мине
Бутыйсыңдыр да әле.
(Казан)


Гөлнара, 1 яшь 5 ай

– Кая киттегез инде
Калдырып ялгызымны?
Кайнар булып чыкты ботка –
Пешерде авызымны!
(Апас, Болын-Балыкчы)


Рүзәл, 6 яшь;
Рушан, 5 яшь.

– Әллү, Рушан! Хәлләр ничек?
Уяндыңмы йокыдан?
– Сине төштә күрдем әле...
Һәм уяндым... куркудан!
(Мөслим, Баланлы)

Нур Гайсин

Көчек

– Күр, әни, безнең көчекне
Саздан ятып су эчә,
«Кайнамаган су йотарга
Ярамый», – диден кичә.

Чирләрмен диеп курыкмый,
Тәне таза, янәсе;
Миндәй тәртипле булырга
Өйрәтмәгән әнисе.

Кадерле дуслар!

Журналның урта битен иплəп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез сары сызыклар буенча бөкләгез дә килеп чыккан кисәкләрне бит саннарына карап китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төпләп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Минем йонтәс маэмаем



Габдулла Тукай

Ялкау маэмай

Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә,
Җитезләнә, уйный, һаман йөгерә, өрә;

Карый миңа мәхәббәтле күзе белән,
Гүя уйныйк дигән була, гүя көлә.

Кайвакыт ул ята тәмле ашап, туеп,
Ал аяклары өстенә башын куеп;

Аны шунда чебен халкы тынычсызлый,
Ялкау маэмай! Ул аларны тормый куып.

Чебеннәрне астан гына карап ята,
Ярты йомык күзен генә ялтырата;

Бервакыт ул колак артын торып кашый,
Чебен халкы шунда тиз-тиз кача башлый.





Ләбиб Лерон

Акбай менгән читәнгә

(Әкият)

Ни өчен әтәч эт булып өрми, ә эт әтәч булып кычкырмый?

Әгәр әтәч эт булып өрә белсә, аны шундук эт оясы янына бәйләп куячаклар һәм аңа йортны, каралты-кураны сакларга кушачаклар. Ә инде эт «Кикрикук», – дип кычкыра белсә, ул читәнгә яисә койма башына менәргә тиеш була түгелме соң? Ләкин минем үз гомеремдә читәнгә менгән этне күргәнем юк! Ә синең?

Менә бит хикмәт нидә!

Табиб этләр

Борынгы дөнья әсәрләрендә дәва алласы Асклепий белән бергә этләр дә еш сурәтләнә. Әлеге этләр авыруларның яраларын телләре белән ялап дәвалаганнар. Эт селәгәендә лизоцим дигән матдә бар икән. Лизоцимның хәтта этнең күз яшьләрендә дә булуы ачыкланган.

Урта гасырларда кешеләр сәламәтлекләрен ныгыту өчен эт сөте дә эчкәннәр.



Рәссам **Светлана Ибраһимова**

Кадерле дуслар!

Журналның урта битен ипләп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә килеп чыккан хисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач булгач, чын китап булсын – уртасын ике урыннан тәпләп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Әнәс Хәсәнов

Бабай



Әйтә куйды әбисенә:
– Безелдәмә, чебен күк!
Җыештырып ал өстәлне,
Әйдә тизрәк, ашем күп.

Кәшәкәне кая куйдың,
Шунда торса, тешлиме?
Мультфильмнар карыйсым бар,
Телевизор эшлиме?

Чәең кайнар, сөтең салкын –
Җылытып куймагансың.
Мине бүген дә соң гына
Кайтыр дип уйлагансың.

Ялкауландың син, әбекәй,
Карап-карап торам да.
Минем янга дустым керә,
Бар чыгып тор урамга.

Су кайнатып кыяр тозлый,
Себергәч ишегалдын.
...Еллар буе карап ятып,
Үсәргә соңга калдым.





Сакчы бака

Сазлыкта яши бака,
Кычкыра – бака-ка-ка:
Сазда барчагыз бата,
Мин батмыйм, мин бит бака.

Баткаклыкка кермәгез,
Сазга бата күрмәгез.
Сакта тора ул бака,
Кисәтә – бака-ка-ка.

Җилгә ни булган?

Безнең авыл җиле шук –
Әле исә, әле юк.
Бүген аңа ни булган?
Тузан туздыра юлдан.
Әллә йокысы калган,
Әллә ял итеп арган.

Сәлимгә ничә яшь?

Кат-кат санадык кичә дә –
Сәлимебез соң ничәдә?
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Кичә генә иде бишәү.

Бүген бер бармак югалган,
Әллә инде төшеп калган,

Юк икән, юк, менә ич ул,
Зур үс, Сәлим, бәхетле бул.

...Оның әре кыяфәтле,
Чөеп читкә сумкасын,
Бәтәрләгәч иплә кенә
Кәтлитләрен, сумсасын,



Бабай

Безнең бабай бик яшь әле –
Җыерчык юк битендә.
Әби көлә: җыерчыксыз
Бабай булмый бит инде.

Бабай әйтә: әбиләрнең
Җыерчыгы — битенә,
Бабайларның җыерчыгы
Җыела баш миенә.

Минем бабай шундый шаян,
Тагын шаярта димме?
Баш миендә җыерчыклар
Буламыни соң инде?

– Шәбрәк эзлә. Алар, улым,
Эчкә качкан, шул гына.
– Эзлим, юк ич. Синең башың
Карбыз кебек, шоп-шома.

Сез ни әйтерсез икән?

Күптән түгел бер укучы
Кайтып керде дәрестән.
Әбисе йөгереп килде:
– Улым кайткан, фәрештәм.

Җаным, бәгърем, утыр, аша,
Карының бик ачтымы?
Подъезд ишеген үзеңме,
Күрше-фәлән ачтымы?

Башкайларың авыртмыймы?
Җылытып сөт биримме?
Ашмы, боткамы, сумсамы,
Каймак алып килимме?

Ботинкаң кысан түгелме,
Туңмадымы кулларың?
Ничек чыктың урамнарның
Машиналы юлларын?

Үсәргә соңга калдым

Минем әни бигрәк уңган,
Ошый ул һәр кешегә.
Иртән торып, тел йотарлык
Тәмле ашлар пешерә.

Сыер сава, мунча яга,
Идән юа, аннары
Оек бәйли, куып кайта
Күл буена казларны.

Җиләкләргә су сипкәчтен,
Ашата тавыкларны.
Без ашагач, ялт иттерә
Буялган савытларны.

Каймак изеп, май төшерә,
Кер уа җитез генә.
Чүп утагач, кибеткә дә
Барып кайта тиз генә.

...Ышанмагыз бу хәлләргә,
Уйдырма гына дисәм,
Ялгышаммы, әллә юкмы,
Сез ни әйтерсез икән?



Сак булыгыз урамда

Шәһәрдә күп машина,
Бары да бик ашыга:
Троллейбус, трамвай...
Тыз-быз чаба, ай-һай-һай!

Тротуарда йөрмәгез,
Кызыл утка кермәгез.
Яшеле янса – рөхсәт,
Карап кына чык, Әсгат.

Башта син сулга кара,
Аннары уңга кара.
Әнә Вил дөрес бара,
Белдеңме инде, Сара?

Таза, дәү булып үсәр,
Юлда сак йөргән бала.





«Һау-һау! Һау!» — диләр...

(Әз—мәз тарих)

Эт борынгы кеше кулга ияләштергән җан ияләренең иң тәүгеләреннән санала. Этләрнең кулга ияләштерелүе таш гасырда, ягъни безнең эрага кадәрге 10-15 гасырларга карый дип фаразлана.

Галимнәр дөньяда этләрнең 282 төре барлыгын исәпләгәннәр. Доберман, ройтвейлер, дог, сенбернар, ризеншнауцер, такса, эрдельтерьер... — болар дөньяда киң таралган этләрнең кайбер төрләре генә...

Табышмаклар

Кешенең дусты, йортның сакчысы.
Йөгерә дә балта сабы өстенә утыра.

(Эт.)

Дүрт колгага бер кармак.
Дүрт тал-агач төбендә
кәкре кое сиртмәсе.

(Этнең тәпиләре һәм койрыгы.)

Йонлач көчек

Әнә ята йонлач көчек,
Борынын сузган ул ничек!
Йоклаганга да охшый,
Әллә юриме мышный?
Уятыйк үзен, торсын!
Нәрсә булса да булсын!



Нух көймәсен эт коткарган

(Риваять)

Бөтен дөньяны су баскан дәвер. Нух көймәсендә көтмәгәндә тишек хасил була. Шул вакытта көймәдә булган бер эт, хәлнең һәлакәт белән тәмамланачагын аңлап, әлеге тишеккә борынын тыга. Шулай итеп ул көймәгә су үтүне тоткарлый. Эт борыны шуннан соң һәрвакыт юеш һәм салкын булып калган, имеш...

Сүз уңаеннан, эт йоклаганда һәм авырган чакта гына аның борыны коры, кайнар була.





Яшел эт тә була икән


(Кызык-мызык мәгълуматлар)


1984 елда Италиядә яшел көчек дөньяга килә. Мондый сирәк очракны нәселнең генетик үзгәреш кичерүе белән аңлаталар.

Этләр аракы эчкән кешеләрне яратмыйлар. Андыйларга алар аяусыз ташланалар.

Ризыкта тоз аз күләмдә булганда, этләр туфрак ашыйлар, агач каерысы кимерәләр.

Эт сөтендә май һәм аксым күп, углевод аз. Бер литр сөттә 4,4 мг тимер бар. Бу сыер сөтеннән 7-8 мәртәбәгә артык дигән сүз.








Бу матур рәсемнәрне Казаннан 7 яшьлек Диләрә Әхмәдуллина ясаган.











Йөрәкләрдән йөрәкләргә күпер ул

Кадерле дуслар!


Безнең «Салават күпере» – күк гөмбәзендәге гаҗәеп төсләр балкышы гына түгел. Серле, сихри, могҗизалы күпер ул. Ул – күңелләрне күңелләргә, йөрәкләрне йөрәкләргә тоташтыручы күпер дә. Хәер, менә бу хатларны укысагыз, моның шулай икәненә үзегез дә ышанырсыз.

«Беркөнне күрше кызы безгә «Салават күпере» журналы күтәреп кергән. «Апай, карале, сезнең Лилия түгелме соң бу?» – ди. Журналга карасам, үләмбетәм, шул үзе – оныгым Лилия. Мин бүләк иткән матур күлмәген кигән. Елмаеп карап тора. Курчагы да елмая. Рәсем астына бик матур шигырь дә язгансыз. Үзләре кунакка еш кайтып торсалар да, бик сагынам кызымны. Журналдагы рәсемен күргәч, үзен күргән күк булдым.


Ф.Абдуллина.

Арча районы».

Ошбу кушбиттәге рәсемнәрне В. Алексеева җитәкчелегендәге сәнгать түгәрәгенә йөрүче балалар (Казан) ясаган.




Диләрә Сәгыйдуллина, 6 яшь



Элина Миңнуллина, 7 яшь

Ә менә бу хат Балтач районы, Борнак авылында яшәүче Энҗе Габделәхәтовадан. Хәтерлисездер, ул журналыбызда оештырылган «Күзгә күренмәс кеше» дигән хикәя-әкият язу бәйгесендә җиңеп чыккан иде. Без аңа вәгъдә иткән зур, матур курчак җибәрдек.

«Матур курчак җибәрүегез өчен бик зур рәхмәт. Мин курчагымны бик яратам. Түр башында гына утыртам. Урын җәеп йоклатам. Балалар бакчасына да бергә йөрдек. Курчакны тәрбияче апалар да, дусларым да бик ошаттылар. Курчакка багышлап әбием белән бергә шигырь дә яздык.



Ксюша Викторова, 7 яшь

Сеңлем тарта, курчак миңа,
Мин тартам, курчак миңа.
Чыкты китте тартмасыннан курчагыбыз,
Тартма миндә, ә курчагым сеңлемдә.


Әй, сеңлем, әле бит син бик кечкенә,
Әле сиңа була тик өч кенә.
Син ашыкма, дәү булырбыз икебез дә,
Әкиятләрне язарбыз икебез бергә.

Ходай кушып, кабат приз булса,
Икебезгә ике курчак килсә,
Ул чагында инде мин дәү булсам,
Курчагымның соң берсе булыр кемгә!

Энҗе Габделәхәтова».



Глеб Бычков, 7 яшь



Дайяна Миңнебаева, 5 яшь

АЙ ТУГАН ҺӘМ АЙ ТУЛГАН

Балалар, сезнең яңа туган Айны күргәнегез бармы? Ә тулган Айга сокланганыгыз? Күзәтеп карагыз әле, нечкә генә булып Ай туа, ул әкренләп үсә, зурая, ярымтүгәрәк, аннан соң түм-түгәрәк була. Һәм кабат кими башлый. Яңа туган Айдан башлап, икенче Ай туганга кадәрге вакыт аралыгы – нәкъ бер ай була. Шул вакыт эчендә (егерме тугыз көн + ярты көн тирәсе) Ай Җир тирәли тулы бер әйләнеш ясый. Бу – якынча, дүрт атна һәм көн ярым вакыт.

Римлылар һәр айга бер яки ике көн өстәп, унике айлык календарь уйлап тапканнар. Шулай итеп ел барлыкка килгән.

КАЙСЫ АЙДА НИЧӘ КӨН?

Кайсы айда ничә көн икәнлеген белер өчен, кулдагы бармаклардан да файдаланып була (баш бармак катнашмый). Имән бармакны гыйнвар дип атыйк. Имән һәм урта бармаклар арасы – февраль... Шулай дәвам итәбез дә июльне санагач, августта кабат имән бармакка кайтабыз. Бөтен бармак-айлар – 31, ә бармак араларына туры килгәннәре (февральдән кала) – 30 көннән тора.

Февраль 28 көннән, ә дүрт елга бер 29 көннән килә.

Һәр айның үз исеме бар. Гыйнвар аеннан Яңа ел башлана.

Гыйнвар, Февраль, Март, Апрель, Май, **Июнь, Июль, Август,** Сентябрь, Октябрь, Ноябрь, **Декабрь.**

Һәр айның үз холкы да бар. Килешәсезме? Әйтик, июль – кайнар (иң эссе ай), август – юмарт (җиләк-җимеш өлгерә)... Уйлап карагыз әле, гыйнвар нинди була? Май? Ә октябрь?

Синең туган көнең кайсы айда? Кайсы айда туганга карап, кешеләрнең нинди йолдызлыкта туганын да билгелиләр.

Йолдызнамәләр турында ишеткәнең бармы синең?

Ә менә ул хакта киләсе сәхифәбездә сөйләшербез.

Вакыт иленә сәяхәт дәвам итә.

Илсөяр ИКСАНОВА



Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА

Зиннур ХӨСНИЯР

Алмачуар әкияте

Борын-борын заманда атлар гел алмачуар, ягъни аксыл таплы җирән яки күк төстә генә булган. Алмачуар атлар бик гайрәтле, елгыр булган, җиргә бассалар, тоякларыннан ут чәчрәгән, кешнәп җибәрсәләр, күк күкрәгән. Менә шуннан аларның нинди гаярь икәнлекләрен күзаллап кара инде син! Бия кызлары шулчаклы сылу булган, баскан җирләрендә уйнап торалар ди. Айгыр егетләре шултиклем көчле ди ки, әгәр талпынсалар, айга чаклы сикерә алганнар.

Алмачуар атлар бик тату, бәхетле яшәгәннәр. Татар бугазыннан алып Кара диңгезгә чаклы үзләренең аерым биләмәләре булган. Ул биләмәләргә берәүнең дә аяк басарга йөрәге җитмәгән. Әлбәттә, алмачуар атлар дип шүрләгәннәр шул. Алар үзләре дә чит биләмәләргә кызыкмаганнар.

Бик тырыш булган ди бу атлар. Көн-төн ару-талуны белми эшләгәннәр, дәүләт-биләмәләрен ныгытканнар, байлыкларын арттырганнар. Тырышып эшләгәч, тормышлары да бик мул булган, ачлык дигән нәрсәне белмәгәннәр, һәммәсенең аерым абзары булган.

Алмачуар атларның үзләре сайлап куйган ханнары да бар икән. Хан бик акыллы ди, гадел ди. Кардәшләре белән бик матур идарә иткән. Аны хөрмәтләгәннәр һәм берсүзсез буйсынганнар. Кыскасы, тормышлары бик көйле барган алмачуарларның.

Менә шулай матур гына гомер кичеп ятканда күрше биләмәләрдә яшәүче башка хайваннар аларның тормышларына, байлыкларына кызыга башлаган. Бигрәк тә күрше урманнарда яшәп ятучы кабан дуңгызлары еш каныга икән. Бу чучкалар үзләре бик ишле ди, көн саен үрчеп торганнар, ләкин бик ялкаулар икән ди. Җир сөрмәгән алар, иген икмәгән, урманда тик кырмыска ояларын туздырып йөргәннәр. Эссе көннәрдә пычрактан чыкмыйча аунап яталар ди. Кыскасы, ашау урманнан, үлем Ходайдан булган боларның.

Ялкау булгач, ашарларына да такы-токы гына икән инде чучка халкының. Шуңа күрә алар бик еш күрше биләмәләргә һөҗүм итеп, аларның байлыкларын талап, тамакларын туйдыралар ди.

Кабаннар ике төрле булган: ак дуңгызлар һәм кара дуңгызлар. Ләкин алар бер-берсеннән төсләре белән генә аерылган. Холыклары, кылган гамәлләре берүк төрле икән: һәммәсе дә ялкаулар, барысы да караклар һәм сугыш чукмарлары ди.

(Дәвамы киләсе санда.)




Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Башваткычлар



Бу рәсемдә нинди сүз яшерелгән?



Бу рәсемдә ничә квадрат, ничә өчпочмак?



Бу зур балыкта ничә балык?

Бу агачтан бер-берсенә охшаган ике яфракны тап.



Аермаларны тап.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Салават күпере

8–9(149–150) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Эльмира ГАЛИЕВА (9 яшь)
һәм Альберта БАРСУКОВА (8 яшь)
рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 29.7.2002 ел.
Басарга кул куелды 29.7.2002 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 14948 данә. Заказ Б-419.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953





Ләбиб Лерон

Сизми калганбыз...



Җәй узмас, диеп
Уйлаган идек:
Таңнан кичкәчә
Уйнаган идек.

Сизми калганбыз
Көз килгәнен дә,
Тәүге яфраклар
Өзелгәнен дә...

Әле һаман да
Сизмәс идек без,
Көзнең килгәнен
Белмәс идек без –

Кыңгырау чыңы
Искә төшерде:
Көзнең килүен
Шунда төшендек.